**ГЛАВА**
**Кудашевского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Кодаш авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.10.2019 Кодаш авылы № 4

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кодаш авыл җирлеге Биектау авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кодаш авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кодаш авыл җирлеге башлыгы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кодаш авыл җирлеге башлыгы к а р а р б и р д е:

1.2019 елның 14 нояберьдә Биектау авыл клубы бинасында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 13.00 сәгатькә билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны располарга: Кодаш авыл җирлегендә теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2020 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә юнәлтергә Сез ризамы:

1. Биектау авылының Колхоз урамнына вак таш җәю.
2. Биектау зиратын койма белән эйләндереп алу.
3.Биектау авылының Сәйдәш урамында су трубаларын алыштыру.
4. Биектау авылына гадәттән тыш хәлләрдә халыкка хәбәр итү өчен тавыш сигнализациясе сатып алу һәм урнаштыру.
5. Биектау авылына су башнясына насос алу.

«ӘЙЕ» «ЮК»

3.Кодаш авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыру һәм үткәрүне йөкләргә.

4.Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштыру, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан

Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм http://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтында.бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Ф.М. ШАКИРОВ

Совет Кудашевского сельского поселения
Кодаш авыл жирлеге Советы
ИНН 1601002501
АГРЫЗСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН • ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ